ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛОТОЛКИШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422966, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
с. Малый Толкиш, ул. Центральная, 17

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
КЕЧЕ ТАЛКЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГІ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422966, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Кече Талкыш авылы,
Центральная ур., 17

тел. 884342 3-37-64, e-mail: Mtolk.Ctp@tatar.ru

***Постановление*** ***Карар***

2022 елның 29 июле № 9

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 30 мартындагы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 30 мартындагы 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 3 пунктта «, муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 12 пунктның 2 абзацында «, муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;
1.3. 12 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының биш ел эчендә нисбәте белән характерлана торган ташламаларга түләүчеләр тарафыннан ихтыяҗ булу.»;
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Кече Талкыш авыл җирлеге
башлыгы Г.Н. Федотов